| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 Баулы шәһәре № 27

Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өлешендә Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасы һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү Тәртибен раслау турында» 2022 елның 26 октябрендәге 73 номерлы карарын;

- «Баулы шәһәр Советының 2022 елның 26 октябрендәге 73 номерлы карары белән расланган, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе һәм аларның гаилә әгъзалары вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан

расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 2 февралендәге 86 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенч: http://www.pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында: http://www.bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының Икътисадый үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров